МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное образовательное учреждение
высшего образования
"Казанский (Приволжский) федеральный университет"
Высшая школа татаристики и тюркологии им.Габдуллы Тукая

УТВЕРЖДАЮ
Проректор по образовательной деятельности КФУ
Проф. Д.А. Таюрский
_______________ «___»________20__г.

*подписано электронно-цифровой подписью*

# Программа дисциплины

Практикум по родному языку Б1.В.ДВ.5

Направление подготовки: 44.03.05 - Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)
Профиль подготовки: Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (китайский)
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: очное
Язык обучения: русский

**Автор(ы):**
Хуснутдинов Д.Х.

**Рецензент(ы):**
-

**СОГЛАСОВАНО:**
Заведующий(ая) кафедрой: Галиуллина Г. Р.
Протокол заседания кафедры No ___ от "____" ___________ 201__г
Учебно-методическая комиссия Института филологии и межкультурной коммуникации им. Льва Толстого (Высшая школа татаристики и тюркологии им.Габдуллы Тукая):
Протокол заседания УМК No ____ от "____" ___________ 201__г

Регистрационный No 902386218

Казань
2018

## Содержание

1. Цели освоения дисциплины
2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы
3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля
4. Структура и содержание дисциплины/ модуля
5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения
6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов
7. Литература
8. Интернет-ресурсы
9. Материально-техническое обеспечение дисциплины/модуля согласно утвержденному учебному плану

Программу дисциплины разработал(а)(и) доцент, к.н. (доцент) Хуснутдинов Д.Х. кафедра татарского языкознания Высшая школа татаристики и тюркологии им.Габдуллы Тукая , Domer1982@mail.ru

## 1. Цели освоения дисциплины

Целью курса является повышение грамотности и совершенствование всех видов речевой деятельности студентов (т.е. овладение орфографическими, пунктуационными, лексико-грамматическими и стилистическими нормами татарского языка). На занятия для анализа и закрепления также выносятся те факты языка, где возможно прогнозирование ошибок у учащихся.

## 2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы высшего профессионального образования

Данная учебная дисциплина включена в раздел " Б1.В.ДВ.5 Дисциплины (модули)" основной образовательной программы 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки) и относится к дисциплинам по выбору. Осваивается на 1 курсе, 1 семестр.

Данная учебная дисциплина входит в профессиональный цикл (раздел Б3ДВ2). Дисциплина изучается на первом курсе в I-II семестрах, имеет тесные связи с дисциплиной "Практикум по орфографии и орфоэпии татарского языка", "Основной (татарский) язык", "Развитие устной и письменной татарской речи" и т.д.

## 3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

В результате освоения дисциплины формируются следующие компетенции:

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ОК-1 (общекультурные компетенции) | владеть культурой мышления, способность к обобщению, анализу, восприятию информации, постановке цели и выбору путей её достижения |
| ОК-14 (общекультурные компетенции) | готов к толерантному восприятию социальных и культурных различий, уважительному и бережному отношению к историческому наследию и культурным традициям |
| ОК-3 (общекультурные компетенции) | способность понимать значение культуры как формы человеческого существования и руководствоваться в своей деятельности современными принципами толерантности, диалога и сотрудничества |
| ОК-4 (общекультурные компетенции) | способность использовать знания о современной естественнонаучной картине мира в образовательной и профессиональной деятельности, применять методы математической обработки информации, теоретического и экспериментального исследования |
| ОПК-3 (профессиональные компетенции) | владеет основами речевой профессиональной культуры |
| ОПК-6 (профессиональные компетенции) | способность к подготовке и редактированию текстов профессионального и социально значимого содержания |
| СК-3 | овладение новыми языковыми средствами (фонетическими, орфографическими, лексическими, грамматическими) в соответствии с темами, ситуациями обучения; увеличение объема активной лексики; умение пользоваться различными словарями |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| СК-6 | дальнейшее развитие учебных умений и навыков, приобретенных в общеобразовательной школе; ознакомление студентов приемами самостоятельного изучения языка и культуры татарского народа с использованием инновационных информационных технологий |
| СК-7 | овладение речевой деятельностью и основами культуры устной и письменной речи; умение соотносить языковые средства с конкретными сферами, ситуациями, условиями и задачами общения |

В результате освоения дисциплины студент:

1. должен знать:

нормы и принципы орфографии и пунктуации татарского языка; закономерности нормативного и вариативного использования языковых единиц в практике татарской речи

2. должен уметь:

реализовывать на практике полученные знания и навыки; целенаправленно работать с различными словарями; употреблять в речи системно организованные грамматические и лексические средства, необходимые для построения связного текста

3. должен владеть:

основными методами и приемами исследовательской и практической работы в области языкознании; демонстрировать способность и готовность практическому применению полученных знаний при решении профессиональных задач; обладать практическими навыками орфографии и пунктуации

4. должен демонстрировать способность и готовность:

дальнейшее развитие учебных умений и навыков, приобретенных в общеобразовательной школе; ознакомление студентов приемами самостоятельного изучения языка и культуры татарского народа с использованием инновационных информационных технологий

- овладение речевой деятельностью и основами культуры устной и письменной речи; умение соотносить языковые средства с конкретными сферами, ситуациями, условиями и задачами общения

## 4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

Общая трудоемкость дисциплины составляет 2 зачетных(ые) единиц(ы) 72 часа(ов).

Форма промежуточного контроля дисциплины зачет в 1 семестре.

Суммарно по дисциплине можно получить 100 баллов, из них текущая работа оценивается в 50 баллов, итоговая форма контроля - в 50 баллов. Минимальное количество для допуска к зачету 28 баллов.

86 баллов и более - "отлично" (отл.);

71-85 баллов - "хорошо" (хор.);

55-70 баллов - "удовлетворительно" (удов.);

54 балла и менее - "неудовлетворительно" (неуд.).

### 4.1 Структура и содержание аудиторной работы по дисциплине/ модулю

### Тематический план дисциплины/модуля


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 1. | Тема 1. Орфография. Понятие об орфографии. Основные принципы орфографии | 1 | 1-3 | 0 | 3 | 0 | |
| 2. | Тема 2. Употребление прописных букв | 1 | 4-6 | 0 | 3 | 0 | |
| 3. | Тема 3. Разделительный ъ и ь | 1 | 7-8 | 0 | 3 | 0 | |
| 4. | Тема 4. Общие правила написания сложных слов. Сложные имена существительные и прилагательные, дефисное и слитное написания | 1 | 9-11 | 0 | 3 | 0 | Контрольная работа |
| 5. | Тема 5. Правописание интернациональных слов | 1 | 12-13 | 0 | 2 | 0 | |
| 6. | Тема 6. Правописание имен числительных | 1 | 14-15 | 0 | 2 | 0 | |
| 7. | Тема 7. Правописание местоимений. Правописание отрицательных местоимений | 1 | 16 | 0 | 2 | 0 | |
| 8. | Тема 8. Правописание глаголов. Личные окончания глаголов | 1 | 1 | 0 | 3 | 0 | |
| 9. | Тема 9. Правописание междометий и звукоподражательных слов | 1 | 2 | 0 | 3 | 0 | |
| 10. | Тема 10. Пунктуация как раздел науки о языке. Пунктуация предложения и пунктуация текста | 1 | 3 | 0 | 3 | 0 | |
| 11. | Тема 11. Основные типы внутрипредложенческих знаков препинания (грамматические, интонационные и семантические) | 1 | 4 | 0 | 3 | 0 | |
| 12. | Тема 12. Знаки препинания в конце предложения | 1 | 5 | 0 | 3 | 0 | |

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 13. | Тема 13. Знаки, прерывающие предложение | 1 | 6 | 0 | 3 | 0 | |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 1 | | 0 | 0 | 0 | Зачет |
| | Итого | | | 0 | 36 | 0 | |

### 4.2 Содержание дисциплины

### Тема 1. Орфография. Понятие об орфографии. Основные принципы орфографии

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Кириллицада татар теленә карта берничә төркем проблема билгеләп чыгарга мөмкин. Беренче төркем проблемалар алфавит һәм сөйләм белән аермасы нигезендә барлыкка килгән проблемалар. Икенче төркем, алынмалар һәм совет чорында рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләр язуы проблемасы. Һәм өченче төркем: кайтарылган сүзләр язуы проблемасы. Татарча орфографиясендә һәм язарга өйрәтүдә төп кыенлыклар булып түбәндәгеләрне билгелибез: 1) аваз белән хәреф еш кына туры килми; 2) татар телендә күпчелек сүзләрнең язылышын сингармонизм законы (рәт гармониясе) билгеләсә дә, алынма һәм кушма сүзләр бу законга буйсынмыйлар; 3) ассимиляция, диссимиляция, редукция, иренләшү, элизия очраклары сүзнең әйтелеше белән язылышы арасында зур аерма булуы турында сөйлиләр; 4) рус орфографиясендә фонетик-морфологик язылыш өстенлек итә, татар телендә фонетик һәм морфологик язылыш төп принциплары булса да, алдагы фонетик үзгәреш төрләре боларга каршы килә.

### Тема 2. Употребление прописных букв

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Мөстәкыйль җөмлә башындагы һәм шигырь юлы башындагы сүзләр, шулай ук ялгызлык исемнәр баш хәрефтән башланалар. Ялгызлык исемнәр бик күп төрле була, аларда төрлечә язылыш күзәтелә, шуңа күрә ул төрләрне аерып күрсәтү сорала. Кеше исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, псевдонимнар, кушаматлар баш хәреф белән башлана: Мөхәммәт Мәһдиев, Гөлсем Нурмөхәммәт кызы Сөләйманова, Хөснетдинов Дамир Хәйдәр улы һ.б. Килешүләрдә һәм башка төрле документларда кулланылган шартлы ялгызлык исемнәр баш хәреф белән башлана: Автор, Заказчы, Нәшрият (автор белән төзелгән килешүләрдә) һ. б. Рәсми хатларда һәм эш кәгазьләрендә берлек сандагы затка хөрмәт белән әйтелгән Сез сүзе дә баш хәрефтән языла: Без Сезне ихлас күңелдән котлыйбыз һәм Сезгә олы рәхмәтебезне белдерәбез. Хайван, кош-корт кушаматлары баш хәреф белән башлана: Актүш, Мияубикә, Актәпи һ.б. Мәсәлләрдә, әкиятләрдә һәм башка әдәби әсәрләрдә уртаклык исем белән бирелгән персонаж исемнәре, ялгызлык исемгә әйләнеп, баш хәреф белән башлана: Шуннан Арыслан Төлкегә Бүрене чакырырга кушты, бүре килмәде. (Әкият.) Географик һәм астрономик атамалар, төрле топонимнар (дәүләт, шәһәр, авыл, елга, тау, күл, диңгез, урам, мәйдан, йолдыз, планета исемнәре һ.б.) баш хәреф белән башлана. Әгәр алар аерым яки сызыкча аша языла торган берничә сүздән төзелгән булсалар, андагы төр белдерү өчен туры мәгънәсендә кулланылган сүзләр - юл хәрефе белән, калган кисәкләр баш хәрефтән башлана: Азия, Чулман, Татарстан, Америка Кушма Штатлары, Азатлык мәйданы, Саба районы, Мамалай авылы, Җидегән йолдыз һ.б. Республика һәм дәүләтләрнең рәсми исемнәрендәге һәр сүз баш хәреф белән башлана: Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе, Кытай Халык Республикасы һ.б.

### Тема 3. Разделительный ъ и ь

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

ъ һәм ь хәрефләренең дөрес язылышы бүгенге көндә шулай ук актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бу хәрефләр нечкәлек-калынлык һәм аеру билгесе буларак кулланылалар. Бу уңайдан "Татар грамматикасы"нда бирелгән билгеләмәне карап китик: Нечкәлек билгесе буларак, ь, беренчедән, рус теленнән кергән сүзләрдә үзенә хәтле килгән тартыкның рус телендәгечә нечкә әйтелешен белдерә. Мәсәлән: ноль, руль, якорь. Икенчедән, ь хәрефе калын итеп укылуы мөмкин булган иҗекләрнең нечкә әйтелешенә ишарә итә. Мәсәлән: табигать, шәфкать (табигъәт, шәфкъәт дип әйтеләләр)". Инде алдарак карап киткәнебезчә, калынлык билгесе буларак, ъ үзенә хәтле килгән г һәм к хәрефләренең кече тел тартыклары [г] һәм [к] ны белдерүләрен күрсәтә. Мәсәлән: мәгънә, нәкъ. Нечкәлек-калынлыктан тыш, бу хәрефләр аеру билгесе буларак та кулланыла дидек: " ь, ъ хәрефләре, е, ю, я алдыннан килгәндә, аеру билгесе ролен башкаралар: е, ю, я хәрефләрен алардан алда килгән тартык авазлардан аерып укырга кирәклекне белдерәләр. Мәсәлән: Ильяс, аръяк, берьюлы, Мисаллардан күренгәнчә, нечкә иҗектән соң - ь, калын иҗектән соң ъ хәрефе язылa." Күп вакыт әлеге хәрефләрнең дөресен сайлап алып язу зур гына кыенлыклар тудыра. Шулай ук ъ һәм ь хәрефләренең бирелгән сүздә нинди роль башкаруларын ачыклау буенча мәшәкатьләр туарга мөмкин. Моннан тыш, ь, ъ хәрефләренең [`] һәмзә тартыгын белдерүләрен онытырга ярамый: мәсьәлә, Коръән. Нәтиҗә ясап әйткәндә, без карап киткән орфографик кагыйдәләр аеруча кыенлык тудыручы өлкәләргә карый. Әлеге дөрес язылыш кагыйдәләре безгә һәрдаим кирәк, без алар белән көндәлек тормышта очрашып торабыз. Әлбәттә, барлык кагыйдәләрне дә күңелдә саклау мөмкин түгел. Ләкин югарыда санап кителгәннәре һәркем мәҗбүри белергә тиешле кагыйдәләр җыелмасы булып тора. Бары тик шушы орфографик кагыйдәләрне үтәгәндә генә дөрес, грамоталы язуга ирешеп була.

**Тема 4. Общие правила написания сложных слов. Сложные имена существительные и прилагательные, дефисное и слитное написания**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Аерым язылалар: икенче кисәге ялгызлык исеме булган яки тартым кушымчасы ялганган кушма исемнәр: Урта Азия, Кама Тамагы, Балык Бистәсе, җир җиләге, кура җиләге һ.б. Кушылып язылалар: 1) кисәкләре аергыч белән аерылмыш мөнәсәбәтендә килеп, ахырында тартым кушымчасы булмаган кушма исемнәр: өчаяк, акшар, көньяк, тимераяк һ.б.; 2) кисәкләре тәмамлык мөнәсәбәтендә булган кушма исемнәр: илбасар, алъяпкыч, башкисәр һ.б.; 3) кисәкләре хәбәрлек мөнәсәбәтендә булган кушма исемнәр: Килдураз, Ходайбирде һ.б.; 4) кеше исемнәре, фамилияләр, кушаматлар: Гөлҗамал, Бибикамал, Гыйлемханов, Актырнак һ.б.; 5) авто-, теле-, фото-, электро-, био-, агро-, микро-, стерео-, фоно-, нео-, кино-, радио- һ.б. шундый кисәкләр белән ясалган кушма исемнәр һәм кыскартылма исемнәр: радиотүгәрәк, стереокөчәйткеч һ.б. Сызыкча (дефис) аша язылалар: 1) кисәкләре мәгънә ягыннан тезүле бәйләнештә булган кушма сүзләр: ата-баба, керем-чыгым, күз-колак, көч-хәл һ.б.; 2) катлаулы фамилияләр, псевдонимнар: Гыйзәтуллина-Волжская, Сәйфи-Казанлы һ.б.; 3) катлаулы үлчәм берәмлекләре: тонна-километр, киловатт-сәгать 4) һ.б; 5) ике халык исеменнән ясалган сүзләр: фин-угор, карел-фин һ.б. ; 6) кайбер кушма географик атамалар: Нью-Йорк, Сарасаз-Баграй һ. б. ; 7) 6) термин өчен алынган шартлы билге яки кыскартылма сүзләрдән соң килгән цифрлар: Т-40, ДТ-54, Ваз-2109 һ.б.

**Тема 5. Правописание интернациональных слов**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Әйтеп киткәнчә, күп кенә рус авазлары татар телендә шул ук хәреф белән билгеләнгән авазларга туры килмиләр. Мәсәлән, "а", "о", "ы", "е". Әмма әле Ә.М. Әхунҗанов тарафыннан канунлаштырылган принцип буенча, рус алынмалары татар теленә үзгәрешсез керәләр. Әлбәттә, аларның язылышы һәм әйтелеше шулай ук рус телендәге кебек булырга тиеш. Бу проблема татар теленә кергән алынмалар саны артуы белән тагын да зарурлана, чөнки икътисади, сәяси-иҗтимагый тормышта үзгәрешләр нигезендә, хәзер бик күп яңа терминнар һәм аңлатмалар кереп бара. Алар бөтенесе дә рус телендәге кебек формалашалар. Бу күренешне яңа чыккан орфографик сүзлектә күзәтергә мөмкин. Монда күп кенә мисал китереп була: принтер, дистрибьютор, секьюрити, монитор һ.б. Әлбәттә, бу проблема татар орфографиясенә, бер яктан, җиңеллек кенә китерә. Чөнки рус телендәге кагыйдәләр турыдан-туры татар теленә күчәләр, һәм мәсьәлә хәл ителә кебек. Әйтик, рус телендәге вариативлык рэкет ? рэкит ? рикет рус телендә рэкет формасында тукталып чишелде. Татар теле бу вариативлыкны кабатлап кына чыга. Әмма, икенче яктан, без монда татар телендәге орфография нигезләренең төп кагыйдәләре бозылуын күзәтә алабыз. Мәсәлән, шул ук әйтелеш һәм язылыш белән зур аерма тууы: дистрибьютор сүзе татар теленә хас түгеллеге билгеле.

**Тема 6. Правописание имен числительных**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Егермедән зуррак саннар һәм вакланмалы саннар аерым язылалар: егерме бер, утыз ике, илле биш, алтмыш җиде һ.б. Чама саннары һәм катлаулы бүлем саннары сызыкча аша язылалар: өч-дүрт (малай), биш-алты (көн), унар-унар һ.б.

**Тема 7. Правописание местоимений. Правописание отрицательных местоимений**

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Кай-, һич-, һәр-, бер- сүзләре белән килгән кушма алмашлыклар кушылып язылалар: кайбер, кайберәү, һичбер, һичкайда, һичнинди, һәрни, һәркем, һәрнәрсә, һәркая, беркем, берни, берничек, бернәрсә һәрнәрсә һ. б. Тезүле бәйләнеш нигезендә ике сүз бергә килеп ясалган кушма яки кабатлаулы алмашлыклар сызыкча аша язылалар: ул-бу, алай-болай, тегесе-монысы, андый-мондый, тегендә-монда, теге-бу, аны-моны һ.б.

**Тема 8. Правописание глаголов. Личные окончания глаголов**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Хәл фигыль белән ярдәмче фигыльдән торган, исем белән ярдәмче фигыльдән торган кушма фигыльләр аерым язылалар: язып бирү, карап сөйләү, сөйли тору, рәхсәт итү, уйлап йөрү, әйтеп ташлау һ.б. Бер үк мәгънәле яки капма-каршы мәгънәле сүзләрне кабатлау рәвешендә ясалган фигыль формалары сызыкча аша язылалар: ала-ала, бара- кайта, киеп-салып, кереп-чыгып һ.б.

**Тема 9. Правописание междометий и звукоподражательных слов**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Кушма һәм кабатлаулы ымлыклар, аваз һәм образ ияртемнәре сызыкча аша язылалар: пес-пес, ах-вах, ау-вау, хоп-хоп, хай-хай, вай-вай, келтер- келтер, шарт-шорт, җилфер-җилфер, келт-келт, пух-пух, голт-голт һ.б'.

**Тема 10. Пунктуация как раздел науки о языке. Пунктуация предложения и пунктуация текста**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Пунктуацией называются правила расстановки знаков препинания и сами знаки препинания. Знаками препинания называются графические знаки, употребляющиеся на письме для расчленения смысловых отрезков текста, синтаксического и интонационного членения речи. Все знаки препинания членят предложение на структурно-грамматические отрезки: запятая разделяет однородные члены, тире - две части бессоюзного сложного предложения, точка завершает повествовательное предложение. Каждый из знаков "читается" и интонационно: запятая в этом предложении требует небольшой паузы, однотипности прочтения разделяемых ею однородных членов, тире свидетельствует о значительной и напряженной паузе, об изменении темпа и тона произнесения второй части; точка - о спокойном понижении голоса и большой паузе.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

**Тема 11. Основные типы внутрипредложенческих знаков препинания (грамматические, интонационные и семантические)**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Главное назначение пунктуации ? способствовать пониманию читателем письменного текста, его структуры, синтаксической и смысловой. Текст, написанный без знаков препинания, читается в три-пять раз медленнее, чем текст оформленный. Пунктуационное правило ? это инструкция, в которой указываются условия выбора знака препинания (т. е. его употребление или неупотребление). Условия выбора знака препинания ? это грамматические, смысловые и интонацион�ные особенности предложений и их частей. Примечание. Место в предложении, где необходима поста�новка знаков препинания, можно найти по опознавательным признакам (приметам). Опознавательные признаки применения пунктуационных правил: 1) морфологические: наличие причастий, деепричастий, междометий, союзов, отдельных частиц; 2) синтаксические: наличие двух и более грамматических основ, обращений, вводных слов, обособленных членов предло�жения, однородных членов, чужой речи; 3) звуковые: произношение со звательной и другими видами интонаций; 4) смысловые: выражение причины и др.

**Тема 12. Знаки препинания в конце предложения**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Нокта түбәндәге очракларда куела: - хикәя җөмләдән һәм тыныч тавыш белән әйтелгән боерык җөмләдән соң; - баштагы бер яки берничә хәрефе белән кыскартылып язылган сүзләрдән соң; - драма әсәрләрендәге персонаж исемнәреннән соң. Сорау билгесе сорау җөмләдән соң куела. Өндәү билгесе көчле тойгы (көчле боеру, үтенү, ялыну, шатлык, соклану, гаҗәпләнү, үкенү, ирония һәм ачулану) белән әйтелгән җөмләдән соң куела.

**Тема 13. Знаки, прерывающие предложение**

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

Күп нокталар цитаталарда төшереп калдырылган сүзләр яки җөмләләр урынына куела, төрле сәбәпләр аркасында сөйләмнең әйтелеп бетмәвен күрсәтү өчен куела. Көчле тойгы белән әйтелгән сорау җөмләдән соң ?! куела.

**4.3 Структура и содержание самостоятельной работы дисциплины (модуля)**

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тема 1. Орфография. Понятие об орфографии. Основные принципы орфографии | 1 | 1-3 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 2. | Тема 2. Употребление прописных букв | 1 | 4-6 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Тема 3. Разделительный ъ и ь | 1 | 7-8 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 4. | Тема 4. Общие правила написания сложных слов. Сложные имена существительные и прилагательные, дефисное и слитное написания | 1 | 9-11 | подготовка к контрольной работе | 3 | контрольная работа |
| 5. | Тема 5. Правописание интернациональных слов | 1 | 12-13 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 2 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 6. | Тема 6. Правописание имен числительных | 1 | 14-15 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 2 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 7. | Тема 7. Правописание местоимений. Правописание отрицательных местоимений | 1 | 16 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 2 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 8. | Тема 8. Правописание глаголов. Личные окончания глаголов | 1 | 1 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 9. | Тема 9. Правописание междометий и звукоподражательных слов | 1 | 2 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Тема 10. Пунктуация как раздел науки о языке. Пунктуация предложения и пунктуация текста | 1 | 3 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 11. | Тема 11. Основные типы внутрипредложенческих знаков препинания (грамматические, интонационные и семантические) | 1 | 4 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 12. | Тема 12. Знаки препинания в конце предложения | 1 | 5 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| 13. | Тема 13. Знаки, прерывающие предложение | 1 | 6 | Изучение дополнительной литературы по теме занятия | 3 | Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена |
| | Итого | | | | 36 | |

## 5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

Рекомендуемые образовательные технологии: практические занятия, самостоятельная работа студентов, контрольная работа, тест, сочинение, изложение, диктант (выборочный, словарный, с грамматическим заданием и др.), диагностирование в начале и конце изучения дисциплины.

При проведении занятий рекомендуется использование активных и интерактивных форм занятий (компьютерных симуляций, деловых и ролевых игр, проектных методик, мозгового штурма, разбора конкретных ситуаций, коммуникативного эксперимента, коммуникативного тренинга, иных форм) в сочетании с внеаудиторной работой.

## 6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

### Тема 1. Орфография. Понятие об орфографии. Основные принципы орфографии

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена , примерные вопросы:

Орфография төзүдә берничә принцип бар: фонетик, морфологик, тарихи-традицион һәм график принциплар. Бу принциплар, телнең фонетик-морфологик үзенчәлегенә карап, төрле телдә төрле дәрәҗәдә кулланыла. Әлбәттә, теориядә дә, практикада да иң яхшы дип танылганы ? фонетик принцип. Ләкин сүз төрләнү белән авазлары күп төрле комбинатор һәм позицион үзгәрешләр кичерә торган телләр (мәсәлән, рус теле) өчен фонетик принцип төп нигез була алмый. Бу телләрдәге аваз үзгәрешләренең һәм чиратлашуларының барысын да күрсәтә башласаң, бер үк тамырдагы сүзләр төрле очракта төрлечә язылыр һәм сүзнең мәгънәсен тиз генә аеру да бик үк мөмкин булмас иде. Шуңа күрә андый телләр өчен беренче чиратта морфологик принцип хас. Билгеле, кайсы гына телдә генә булмасын, орфографиядә бары тик бер генә принцип белән чикләнеп калып булмый. Фонетик принципка нигезләнгән татар язуына да урыны белән морфологик принцип кирәк булып чыга. Безнең орфографиядә бу принцип, башлыча, кайбер сүзләрне һәм кушымчаларны, аларның теге яки бу авазы билгеле позицияләрдә үзгәрүгә карамастан, бер генә формада язуга кайтып кала. Мәсәлән, [з], [н], [л] авазларына беткән сүзләрдә бу тартыклар күрше авазга ияреп, [с], [м], [н], [ң] булып әйтелсәләр дә, яки ике сүз чигендә янәшә сузыкларның берсе йотылса яисә, сузыклар арасына туры килеп, саңгырау тартык яңгырауга әйләнсә дә, бу үзгәрешләр, сүзнең (тамырның, нигезнең яки андагы кушымчаның) мәгънә ачыклыгы югалмасын өчен, язуда күрсәтелми: тозсыз, әнкәй, юк өчен, утынлык, унбер, буранлы сүзләре, тоссоз, әңкәй, утыннык, умбер, буранны түгел, әле язылганча бирелә. Тарихи-традицион принцип гадәттә телнең хәзерге фонетик-морфологик төзелеше белән бик үк тыгыз бәйләнештә булмый. Әлеге принципка карата Х.Р.Курбатов түбәндәге фикерен җиткерә: "Инглиз һәм француз орфографияләре өчен шушы принцип хас. Бу телләрнең орфографияләре моннан берничә гасыр элек төзелеп тә, телдә зур гына үзгәрешләр булуга карамастан, бүгенге көнгә кадәр шул хәлдә калган. Нәтиҗәдә җанлы әйтелеш белән язылыш арасында зур гына аерма килеп чыккан."

**Тема 2. Употребление прописных букв**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена , примерные вопросы:

1. Баш хәрефләр орфографиясенә караган нинди кагыйдәләр беләсез? 2. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешен мисаллар белән аңлатыгыз. 3. Көндәлек тормышта кирәкле нинди эш кәгазьләрен беләсез?

**Тема 3. Разделительный ъ и ь**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена , примерные вопросы:

1. ъ и ь янында нинди тыныш билгеләре куела? 2. Аларның җөмләдә кулланылышы? Тарихи-традицион принцип шулай ук рус язуында да азмы-күпме сизелә (рожь, мышь, идешь кебек сүзләрдә, мәсәлән, ?ь? билгесе шушы принциптан чыгып кына куела). Татар телендә бу принцип меңъеллык тарихы булган гарәп язуында (иске имлада) төп урынны тоткан. Безнең хәзерге орфография ул принциптан бөтенләй үк азат түгел. Аеруча моны без иренләштерү гармониясенең язуда сакланмавында, ул кагыйдәнең реформалаштырылган гарәп имласыннан алып, камилләштерелгән яңалиф орфографиясенә һәм аның аша рус графикасы нигезендәге боронго, көндезгә, соло, төзәлөш, комлок дип әйтелә, борынгы, көндезге, солы, төзелеш, комлык рәвешендә языла.

**Тема 4. Общие правила написания сложных слов. Сложные имена существительные и прилагательные, дефисное и слитное написания**

контрольная работа , примерные вопросы:

1. Татар телендә кайсы сүз төркемнәре исемләшә ала? 2. Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә нинди бәйләүче чаралар кулланыла? 3. Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә нинди бәйләүче чаралар кулланыла? 4. Фигыльнең нинди төркемчәләрен беләсез? График принцип хәзерге чорда барлык телләр өчен диярлек хас, ләкин татар орфографиясендә ул аеруча күзгә ташлана. Чөнки бездә рус теле аша кергән сүзләрнең күбесе, аеруча терминнар, үзләренең тамыр һәм нигез өлешләрендә рус орфографиясендәгечә бирелә: революция, химия, электр һ.б. Хәзерге татар орфографиясендә дифференциацияләнгән язылыш та кулланыла. Ул омонимик очракларны бер-берсеннән аеру өчен кирәк. Байрак (знамя) сүзен бай сүзенең чагыштыру дәрәҗәсеннән аеру өчен, соңгысын баерак дип язу норма булып тора. Түбәндәге мисалларны кушып язуяки язмау аларның мәгънәләрен аера: өч аяк - өчаяк, өч почмак - өчпочмак, биш бармак - бишбармак, ак сакал - аксакал.

**Тема 5. Правописание интерноциональных слов**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена , примерные вопросы:

Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз: 1. Әгәр битләреңнән назлы җилләр иркәләсә, сандугач сайраулары, агач яфраклары лепердәткән авазлар, йөрәгеңә кереп, бәгыреңне өзсә, бел: бу - әниең рухы булыр. 2. Әгәр син шатлансаң, ләззәт алсаң, бәхетеңне тапсаң, бел: һәммәсе дә әниеңнең йокысыз төннәреннән, кайнар күз яшьләреннән, "балам, бәгырь итем"дип күргән ачы газап-михнәтләреннән. 3. Аның гадәте шундый: эшчеләр килеп кергәч, ул аларны карашы белән ишеккә кадәр озатып кала. 4. Габдулла, мәдрәсәдә быелгы укуын төгәлләп, баштанаяк өй эшләренә чумды: ул караңгыда торып, морҗа ачты; мич сүрелгәч, аны менеп япты; абыйсы калдырып киткән салам көлтәләрен бәйләде. 5. "Әни" дип әйттеңме, син инде көчле дә, син инде бәхетле дә.

**Тема 6. Правописание имен числительных**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена , примерные вопросы:

Сезнеңчә кайсы раслау дөрес? а) Исемнәр махсус кушымчалар ярдәмендә предметның, затның башка бер предметка, затка караганлыгын белдерә алалар. б) Исемнәр махсус кушымчалар ярдәмендә предметның, затның башка бер предметка, затка караганлыгын белдерә алмыйлар. 3. 1) минем китабым; 2) минем китап; 3) китабым - бу вариантларның кайсысы предметның I затка каравын белдерә: а) 1) һәм 2) б) 3) в) барысы да

**Тема 7. Правописание местоимений. Правописание отрицательных местоимений**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена , примерные вопросы:

Тел кылычтан үткен, каләм телдән дә үткен - бу мисалдагы үткен сүзе: а) сыйфат б) рәвеш 14. һичкем, бернинди, беркем - бу: а) билгеләү алмашлыклары б) юклык алмашлыклары в) билгесезлек алмашлыклары

**Тема 8. Правописание глаголов. Личные окончания глаголов**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена, примерные вопросы:

Онытмагыз чакырырга бәби туегызга да - әлеге мисалдагы чакырырга сүзе: а) хикәя фигыль б) боерык фигыль в) инфинитив 10. 1) ишегеңнең кайсы якка ачылганын белмәү; 2) күзгә төтен җибәрү - әлеге әйтемнәрнең кайсында исем фигыль кулланылган: а) 1) б) 2) в) икесендә дә

**Тема 9. Правописание междометий и звукоподражательных слов**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена, примерные вопросы:

Җөмләдә барлык теркәгечләр дә а) аерым языла; ә) кушылып языла; б) сызыкча аша языла; в) дөрес җавап юк. 4. Сабан туе ул () халкыбызның гаҗәеп гүзәл бер традициясе. (Ә.Еники) Җөмләдә тыныш билгесенең куелышы кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән? а) ул көчәйтүче сүзе ия янында килгәнлектән, ике арага сызык куела; ә) бернинди дә тыныш билгесе куелмый; б) өтер куела; в) ике нокта куела.

**Тема 10. Пунктуация как раздел науки о языке. Пунктуация предложения и пунктуация текста**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена, примерные вопросы:

Татар телендә тыныш билгеләре нинди принципларга нигезләнеп куела? 2. Алынма сүзләргә кушымчалар ялгауның нинди кагыйдәләре бар? 3. Инфинитив фигыльләргә кушымчалар нинди кагыйдәләргә таянып ялгана? 4. Ялгызлык исемнәренең дөрес язылышына караган нинди кагыйдәләр беләсез?

**Тема 11. Основные типы внутрипредложенческих знаков препинания (грамматические, интонационные и семантические)**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена, примерные вопросы:

Татар телендә тыныш билгеләре нинди принципларга нигезләнеп куела? 2. Алынма сүзләргә кушымчалар ялгауның нинди кагыйдәләре бар? 3. Инфинитив фигыльләргә кушымчалар нинди кагыйдәләргә таянып ялгана? 4. Ялгызлык исемнәренең дөрес язылышына караган нинди кагыйдәләр беләсез?

**Тема 12. Знаки препинания в конце предложения**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена, примерные вопросы:

Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз: 1. Халык, "аһ" итеп, бөтен мәйданы белән кузгалып куйганда, Айван егете әллә кая, мәйдан уртасына ук барып төшкән иде. 2. Диләфрүз шундый кызу йөри: аның калфагы ак яшен кебек безнең ишек турысыннан сызылып үтеп китә. 3. Мансур палатага килеп кергәч, ул аптырап калды. 4. Диләфрүз озын керфекләрен сирпеп бер караса, палата эчләре яктырып киткәндәй була. 5. "Мин матур," - дип мактанмагыз, матурлар. 6. Кояш ятып йоклагач, күзен ача йолдызлар. 7. Кичә яңгыр яуганга, без гөмбәгә бармадык. 8. Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена.

**Тема 13. Знаки, прерывающие предложение**

Опрос и выполнение заданий во время практических занятий и экзамена, примерные вопросы:

Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз: 1. Халык, "аһ" итеп, бөтен мәйданы белән кузгалып куйганда, Айван егете әллә кая, мәйдан уртасына ук барып төшкән иде. 2. Диләфрүз шундый кызу йөри: аның калфагы ак яшен кебек безнең ишек турысыннан сызылып үтеп китә. 3. Мансур палатага килеп кергәч, ул аптырап калды. 4. Диләфрүз озын керфекләрен сирпеп бер караса, палата эчләре яктырып киткәндәй була. 5. "Мин матур," - дип мактанмагыз, матурлар. 6. Кояш ятып йоклагач, күзен ача йолдызлар. 7. Кичә яңгыр яуганга, без гөмбәгә бармадык. 8. Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена.

**Итоговая форма контроля**

зачет

Примерные вопросы к зачету:

Фонетика бүлеге буенча тест:

1. Кайсы төркемдә аваз һәм хәреф саны туры килә?

а) язмыш, әмма, игътибар, салкын;

б) тарих, балык, зәңгәр, эшчәнлек;

ә) кызыл, урындык, сабан, юк;

в) шәһәр, бала, кәгазь, утыру.

2. [а] авазы өлешчә иренләшеп әйтелгән төркемне күрсәтегез.

а) куркак;

б) аэропорт;

ә) кала;

в) уза

3. [р] авазына туры килә торган билгеләмәне табыгыз.

а) тел уртасы, саңгырау;

б) ирен-ирен, яңгырау;

ә) тел алды, сонор;

в) тел арты, саңгырау

4. Тел арты охшашлануы чагылган сүзне күрсәтегез.

а) болында;

б) сүзчән;
ә) күтәренке;
в) урманнар.
5. Әлеге билгеләмәгә кайсы сузык аваз туры килә: алгы рәт, иренләшкән озын сузык аваз.
а) а;
ә) ө;
б)ү;
в) о.
6. Татар язуы нинди принципка нигезләнгән?
а) фонетик принципка;
б) график принципка;
ә) морфологик принципка;
в) тарихи-традицион принципка
7. Юлдан юлга күчерүнең дөрес очрагын билгеләгез.
а) бөгпен-ләй, еа-кый-га, ма-лай, я-зу;
б) бөтен-ләй, ва-кый-га, мал-ай, я-зу;
ә) бө-тен-ләй, ва-кый-га, ма-лай, язу;
в) бө-тен-ләй, вак-ыйга, ма-лай, яз-у
Лексикология бүлеге буенча тест:
1. Лексикалогия нәрсәне өйрәнә?
а) авазларны һәм хәрефләрне;
б) сүзтезмә һәм җөмләләрне;
ә) сүзләрнең ясалышын һәм төрләнешен;
в) сүзләр җыелмасын.
2. Сүзнең лексик мәгънәсен билгеләгез.
а) өстәл ? исем;
б) өстәл ? агачтан ясалган өй җиһазы;
ә) өстәл ? җөмләдә ия;
в) өстәл ? җөмләдә хәбәр.
3. Болар үзара нинди сүзләр?
Баш (кеше башы, агач башы); аяк (кеше аягы, өстәл аягы).
а) синонимнар;
б) купмәгънәле сүзләр;
ә) бер мәгънәле сүзләр;
в) антонимнар.
4. Нинди сүзләр омонимнар дин атала?
а) әйтелеше төрле, мәгънәсе бер үк сүзләр;
б) язылышы бер үк, әйтелеше төрле сүзләр;
ә) капма-каршы мәгънәле сүзләр;
в) язылышы яки әйтелеше бер, мәгънәсе төрле сүзләр
5. Фразеологик берәмлекне табыгыз.
а) Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма,
б) Бүрәнә аша бүре куу.
ә) Өрми дә, җибәрми дә. Ул нәрсә?
в) Ямьле дә соң безнең Идел буйлары!
6. Болар нинди сүзләр?
Казый, зәхмәт, талак, ярлык, золым.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

а) неологизмнар;

б) гомумкулланылыштагы сүзләр;

ә) архаизмнар;

в) эмоциональ-экспрессив лексика

Морфология бүлеге буенча тест

1. Сезнеңчә кайсы раслау дөрес?

а) Морфология бүлегендә аваз һәм хәрефләр өйрәнелә.

б) Морфология бүлегендә сүз төркемнәре өйрәнелә.

2. Сезнеңчә кайсы раслау дөрес?

а) Исемнәр махсус кушымчалар ярдәмендә предметның, затның башка бер предметка, затка караганлыгын белдерә алалар.

б) Исемнәр махсус кушымчалар ярдәмендә предметның, затның башка бер предметка, затка караганлыгын белдерә алмыйлар.

3. 1) минем китабым; 2) минем китап; 3) китабым - бу вариантларның кайсысы предметның I затка каравын белдерә:

а) 1) һәм 2)

б) 3)

в) барысы да

4. Затланышлы фигыльләргә түбәндәгеләр керә:

а) Хикәя, боерык, шарт, теләк фигыльләр.

б) Хикәя, боерык, шарт, сыйфат фигыльләр

в) Хикәя, шарт, теләк, хәл фигыльләр

5. Сандугачлар тавышын тыңладым да / Өзелеп-өзелеп җырлар җырладым - әлеге мисалда да:

а) бәйлек

б) кисәкчә

6. Карт бүре егетне иснәде, / Аптырап күзенә карады - әлеге мисалда хикәя фигыльләр:

а) Билгесез үткән заманда килгән

б) Билгеле үткән заманда килгән

в)Хәзерге заманда килгән

7. Сыйфат фигыльнең:

а) өч (хәзерге, үткән, киләчәк) заман категориясе бар

б) затланышсыз фигыль буларак, заман категориясе юк

8. Бер эшкә дә алдан уйламыйча керешмә - әлеге мисалдагы уйламыйча сүзе:

а) I төр хәл фигыль

б) III төр хәл фигыль

в) IV төр хәл фигыль

9. Онытмагыз чакырырга бәби туегызга да - әлеге мисалдагы чакырырга сүзе:

а) хикәя фигыль

б) боерык фигыль

в) инфинитив

10. 1) ишегеңнең кайсы якка ачылганын белмәү; 2) күзгә төтен җибәрү - әлеге әйтемнәрнең кайсында исем фигыль кулланылган:

а) 1)

б) 2)

в) икесендә дә

11. Кинәт яшен чытырдады - бу мисалдагы кинәт сүзе:

а) сыйфат

б) рәвеш
12. меңләгән, йөзләп, алтылап - бу:
а) җыю саннары
б) бүлем саннары
в) чама саннары
13.Тел кылычтан үткен, каләм телдән дә үткен - бу мисалдагы үткен сүзе:
а) сыйфат
б) рәвеш
14. һичкем, бернинди, беркем - бу:
а) билгеләү алмашлыклары
б) юклык алмашлыклары
в) билгесезлек алмашлыклары
Гади җөмлә синтаксисы бүлеге буенча тест
1. Сүзтезмәләрнең кайсысы исем сүзтезмә булып килгән?
а) ахырдан икенче;
ә) укудан кайту;
б) күп нәрсә;
в) чигелгән сөлге.
2. Нинди саф, нинди матур күңелле егет син! (М. Мәһдиев) Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрен билгеләгез.
а) хикәя җөмлә;
ә) өндәү җөмлә;
б) тойгылы җөмлә;
в) боеру җөмлә.
3. Билгеләмәне дөрес итеп тәмамлагыз: Җөмләдә барлык теркәгечләр дә
а) аерым языла;
ә) кушылып языла;
б) сызыкча аша языла;
в) дөрес җавап юк.
4. Сабан туе ул () халкыбызның гаҗәеп гүзәл бер традициясе. (Ә.Еники) Җөмләдә тыныш билгесенең куелышы кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән?
а) ул көчәйтүче сүзе ия янында килгәнлектән, ике арага сызык куела;
ә) бернинди дә тыныш билгесе куелмый;
б) өтер куела;
в) ике нокта куела.
5. Әйтсен яшьләр (I) менә шулай яшәп (2) Шулай үлсәң иде дөньяда. (М. Җәлил) Җөмләдә тыныш билгеләре дөрес куелган төркемне күрсәтегез.
а) (1) өтер, (2) өтер;
ә) (1) ике нокта, (2) өтер;
б) (1) сызык, (2) өтер;
в) (1) ике нокта, (2) сызык.
6. Әдәби сөйләмгә куелган таләпләрне дөрес күрсәтегез.
а) төгәллек, аңлаеишылык, сафлык, җыйнаклылык, аһәңлелек;
ә) төгәллек, кыскалык, гадилек, терминнарны күбрәк куллану;
б) төгәллек, әдәбилек, фәннилек;
в) төгәллек, синонимнарны, кушма җөмләләрне күбрәк куллану.
7. Матур әдәбият стиленә хас җөмләне күрсәтегез.

а) Кулыбызга корал тотарлык көчебез барында безне моннан беркем дә әсир, кол итеп алып чыга алмас;

ә) Куяннар белән кроликларны куяннар семьялыгына кертәләр;

б)Безнең артык тыйнаклыгыбыз үзебезне күрсәтергә комачаулап килә торган сәбәпләрнең берседер, мөгаен;

в)Әлеге милли тамашада уку алдынгылары да сәхнәгә чыкты.

8. Калын хәрефләр белән бирелгән кисәкнең функциясен билгеләгез: Әллә кайда, әллә кемнәр безнең юашлыктан көлгән кебек. (Г. Афзал)

а) аергыч;

ә) хәбәр;

б) хәл;

в) тәмамлык.

9. Быел яңгыр аз яуды: игендә өмет зур түгел. (Г.Ибраһимов) Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез.

а) иярчен максат җөмлә;

ә) иярчен ия җөмлә;

б )иярчен сәбәп җөмлә;

в) иярчен вакыт җөмлә.

10. Тимер мич шундый кызу итеп ягылган ки (1) ишек янында (2) муенчалап куелган бозау һәм сарык бәтиләре (3) эсселектән әлсерәп (4) сузылып ятканнар. Кайсы төркемдә өтерләр куелырга тиешле урындагы саннар дөрес күрсәтелгән?

а) 1, 3, 4;

ә) 1, 2, 3;

б) 1, 4;

в) 2, 3, 4.

11. Әйтеп калдырасы сүз шул ки, намусны яшьтән сакларга кирәк. (Г. Ахунов) җөмләсендә шул

а) ия;

ә) хәбәр;

б) тәмамлык..

12. Бер дә алай дип уйламый идең бит әле Локман - бу

ә) инкаръ җөмлә;

б) раслау җөмлә.

13. Егет перрон буйлап йөренде дә борчулы кыяфәт белән үз вагоны янына килеп туктады - бу

а) гади җөмлә

ә) кушма җөмлә

14. Илгиз кайтып кергәннән соң, саклык кассаларында эш башланды - бу

а) гади җөмлә

ә) кушма җөмлә

15. Илгизнең басуга барышы иде - бу

а) билгесез үтәүчеле бер составлы җөмлә;

ә) билгеле үтәүчеле бер составлы җөмлә;

б) ике составлы җөмлә

Кушма җөмлә синтаксисы буенча контроль эш (�1) өчен биремнәр:

Бирем �1 Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз:

1. Анда табыш булачачагы алдан мәгълүм иде инде безгә

2. Һәркемгә билгеле: Тукай бик принципиаль кеше булган.

3. Мин шуны гына беләм: ел елга охшамый.

4. Ул ни дисә, шул булыр.

5. Түләве нинди, эше шундый.
6. Иң мөһиме шунда ки, ул бу вакытта өйдә булмаган.
7. Кешеләрнең бөтен хатасы да шунда: алар тарихтан гыйбрәт алмыйлар.
8. Җиргә беренче орлык иңгәнне күрү яхшы фал булып санала.
9. Шундый йомшак күңелле кеше булып чыгарсың дип, һич кенә дә уйламаган идем.
10. Яшь чагында кемне сөйсәң, күңелең шуңарда була.
11. Кайчан яңгыр туктар, анысын әйтүе кыен.

Бирем �2 Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз:

1. Халык, "аһ" итеп, бөтен мәйданы белән кузгалып куйганда, Айван егете әллә кая, мәйдан уртасына ук барып төшкән иде.
2. Диләфрүз шундый кызу йөри: аның калфагы ак яшен кебек безнең ишек турысыннан сызылып үтеп китә.
3. Мансур палатага килеп кергәч, ул аптырап калды.
4. Диләфрүз озын керфекләрен сирпеп бер караса, палата эчләре яктырып киткәндәй була.
5. "Мин матур," - дип мактанмагыз, матурлар.
6. Кояш ятып йоклагач, күзен ача йолдызлар.
7. Кичә яңгыр яуганга, без гөмбәгә бармадык.
8. Уйсу җиргә су җыела, шунда казлар коена.

Бирем �3 Җөмләләргә синтаксик анализ ясагыз:

1. Әгәр битләреңнән назлы җилләр иркәләсә, сандугач сайраулары, агач яфраклары лепердәткән авазлар, йөрәгеңә кереп, бәгыреңне өзсә, бел: бу - әниең рухы булыр.
2. Әгәр син шатлансаң, ләззәт алсаң, бәхетеңне тапсаң, бел: һәммәсе дә әниеңнең йокысыз төннәреннән, кайнар күз яшьләреннән, "балам, бәгырь итем"дип күргән ачы газап-михнәтләреннән.
3. Аның гадәте шундый: эшчеләр килеп кергәч, ул аларны карашы белән ишеккә кадәр озатып кала.
4. Габдулла, мәдрәсәдә быелгы укуын тәгәлләп, баштанаяк өй эшләренә чумды: ул караңгыда торып, морҗа ачты; мич сүрелгәч, аны менеп япты; абыйсы калдырып киткән салам көлтәләрен бәйләде.
5. "Әни" дип әйттеңме, син инде көчле дә, син инде бәхетле дә.

Контроль эш (�2) өчен якынча сораулык:

1. Татар телендә тыныш билгеләре нинди принципларга нигезләнеп куела?
2. Алынма сүзләргә кушымчалар ялгауның нинди кагыйдәләре бар?
3. Инфинитив фигыльләргә кушымчалар нинди кагыйдәләргә таянып ялгана?
4. Ялгызлык исемнәренең дөрес язылышына караган нинди кагыйдәләр беләсез?
5. Татар телендә кайсы сүз төркемнәре исемләшә ала?
6. Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә нинди бәйләүче чаралар кулланыла?
7. Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә нинди бәйләүче чаралар кулланыла?
8. Фигыльнең нинди төркемчәләрен беләсез?
9.

Контроль эш (�3) өчен якынча сораулык:

1. Баш хәрефләр орфографиясенә караган нинди кагыйдәләр беләсез?
2. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешен мисаллар белән аңлатыгыз.
3. Көндәлек тормышта кирәкле нинди эш кәгазьләрен беләсез?
4. Аерымланган аныклагычлар янында нинди тыныш билгеләре куела?
5. Хәлләр кайсы очракта аерымланалар?
6. Татар телендә сызык һәм сызыкча куелу очракларына нинди кагыйдәләр бар?

Имтихан өчен якынча сораулык:

1. Татар телендә сүз төркемнәре
2. Исем сүз төркеме. Грамматик категорияләре
3. Сыйфат сүз төркеме. Асыл һәм нисби сыйфатлар.
4. Сан сүз төркеме. Төркемчәләре.
5. Алмашлык сүз төркеме. Төркемчәләре.
6. Рәвеш сүз төркеме.
7. Затланышлы фигыльләр.
8. Затланышсыз фигыльләр.
9. Хикәя фигыль.
10. Сыйфат фигыль.
11. Хәл фигыль.
12. Исем фигыль һәм инфинитив
13. Аваз ияртемнәре.
14. Бәйлек һәм бәйлек сүзләр
15. Теркәгеч сүз төркеме.
16. Кисәкчәләр. Аларның төркемчәләре.
17. Модаль сүзләр
18. Ымлыклар.
19. Җөмләнең баш кисәкләре. Ия белән хәбәр арасына сызык куелу очраклары.
20. Җөмләнең иярчен кисәкләре буларак тәмамлык һәм аергыч.
21. Җөмләнең иярчен кисәге буларак аныклагыч. Аныклагыч янында тыныш билгеләре.
22. Җөмләнең иярчен кисәкләре буларак хәлләр. Аларның мәгънә ягыннан төркемчәләре.
23. Җөмләнең модаль кисәкләре буларак эндәш һәм кереш сүзләр. Алар янында тыныш билгере.
24. Тезмә кушма җөмлә.
25. Иярченле кушма җөмләләр. Синтетик һәм аналитик төрләре.
26. Иярченле кушма җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре.
27. Иярченл е кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.
28. Катлаулы кушма җөмләләр.

### 7.1. Основная литература:

1. Павлов, А. В. Методологические проблемы современного гуманитарного познания [Электронный ресурс]: учеб. пособие / А.В. Павлов. - М.: ФЛИНТА, 2013. - 325 с. http://www.znanium.com/bookread.php?book=466244

2. Константинова, Л.А. Грамматика русского языка [Электронный ресурс]: Учеб.пособие / Л.А. Константинова, Н.Н. Гончарова, А.Н. Жукова; Под ред. Л.А. Константиновой. - М.: Флинта: Наука, 2011. - 256 с. - Режим доступа: // http://znanium.com/bookread.php?book=304030

3. Козырев, В. А. Современная языковая ситуация и речевая культура [Электронный ресурс]: учеб. пособие / В.А. Козырев, В.Д. Черняк. - М.: Флинта : Наука, 2012. - 184 с. Режим доступа: http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=462837

4. Завалько, Н. А. Эффективность научно-образовательной деятельности в высшей школе [Электронный ресурс]: Монография / Н.А. Завалько. - 2-е изд., стереотип. - М.: Флинта, 2011. - 142 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=406102

5. Соснин, Н. В. Содержание обучения в компетентностной модели ВПО (К освоению ФГОС ВПО) [Электронный ресурс]: Монография / Н.В. Соснин. - Красноярск: Сибирский федеральный ун-т, 2011. - 242 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=443125

### 7.2. Дополнительная литература:

1.Сериков, В. В. Развитие личности в образовательном процессе: монография / В.В. Сериков. - М.: Логос, 2012. - 448 с. Режим доступа: http://znanium.com/catalog.php?bookinfo=469028

2. Соколков, Е. А. Проблемы поликультур и полиязычий в гуманитарном образовании [Электронный ресурс]: монография / Е.А. Соколков, Н.Е. Буланкина. - М.: Университетская книга; Логос, 2008. - 208 с. Режим доступа: http://znanium.com/bookread2.php?book=469068

3. Менеджмент качества образовательных процессов [Электронный ресурс]: Учебное пособие / Э.В. Минько, Л.В. Карташева и др.; Под ред. Э.В. Минько, М.А. Николаевой. - М.: Норма: НИЦ ИНФРА-М, 2013. - 400 с.- Режим доступа: http://znanium.com/bookread.php?book=400881

### 7.3. Интернет-ресурсы:

Белем.ru - http://forum.belem.ru/index.php?showtopic=288

Диссертации - http://rudocs.exdat.com

Татар теле - http://www.tatartele.ru

Татарская электронная библиотека - http://www.kitap.net.ru/

Татарский электронный переводчик - http://tatar.com.ru

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "Практикум по родному языку" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Компьютерный класс, представляющий собой рабочее место преподавателя и не менее 15 рабочих мест студентов, включающих компьютерный стол, стул, персональный компьютер, лицензионное программное обеспечение. Каждый компьютер имеет широкополосный доступ в сеть Интернет. Все компьютеры подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "КнигаФонд", доступ к которой предоставлен студентам. Электронно-библиотечная система "КнигаФонд" реализует легальное хранение, распространение и защиту цифрового контента учебно-методической литературы для вузов с условием обязательного соблюдения авторских и смежных прав. КнигаФонд обеспечивает широкий законный доступ к необходимым для образовательного процесса изданиям с использованием инновационных технологий и соответствует всем требованиям новых ФГОС ВПО.

Компьютерный класс, оргтехника, теле- и аудиоаппаратура; доступ к сети Интернет (во время самостоятельной подготовки).

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 44.03.05 "Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)" и профилю подготовки Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (китайский) .


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Хуснутдинов Д.Х. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
"__" _________ 201 __ г.